РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
«Алькеевского сельского
поселения» Азнакаевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
«Әлкәй авыл җирлеге»
башкарма комитеты

Пер.Советский 44а
с. Алькеево 423309
тел. (885592) 37-4-23

Совет тыкрыгы 44а
Әлкәй авылы,
423309, тел. (885592) 37-4-23

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2022 ел №23

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең кайбер административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 15 мартындагы 9 номерлы «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында», 2022 елның 27 гыйнварындагы 4 номерлы «Юл тамгаларында индивидуаль проектлауның мәгълүмати билгеләрен урнаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында», 2022 елның 27 гыйнварындагы 2 номерлы «Автомобиль юллары турында һәм Россия Федерациясендә юл эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясында билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә автомобиль юллары буйлап авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында», 2022 елның 27 гыйнварындагы 3 номерлы «Автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында», 2022 елның 01 февралендәге 6 номерлы «Социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарлары белән расланган, муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына ,«Торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 1 номерлы карарының 1,2,4 нче кушымтасына 3.3.2.1 пунктларның унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

"Формалаштырылган гаризаны формаль-логик тикшерү мөрәҗәгать итүче тарафыннан соратуның электрон формасы поляларын тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан тутырылган электрон формадагы электрон поля ачыкланганда, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны мәгълүмати хәбәр итү юлы белән сорауның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр итә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http//aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык С.З.Зиннурова